ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

23.06.2020 г. Заинск № 262

**«Татарстан Республикасы муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына керүче зат һәм Татарстан Республикасы муниципаль учреждение җитәкчесе тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакында нигезләмәне раслау турында" 2013 елның 04 апрелендәге 692 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 275 статьясы, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. «Татарстан Республикасы муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына керүче зат һәм Татарстан Республикасы муниципаль учреждение җитәкчесе тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакында нигезләмәне раслау турында" 2013 елның 04 апрелендәге 692 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына (Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 12 маендагы 1124 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 2 пункты 3 абзацында «ел саен, хисап чорыннан соң килүче елның 30 апреленнән дә соңга калмыйча» сүзләрен «ел саен, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру өчен билгеләнгән срокларда» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. Нигезләмәнең 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Муниципаль учреждение җитәкчесе үзе тапшырган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрдә күрсәтелмәгән яисә нинди дә булса белешмәләр күрсәтелмәгән яисә хаталар булган очракта, ул әлеге Нигезләмәнең 2 пунктында күрсәтелгән срок тәмамланганнан соң бер ай эчендә төгәлләштерелгән белешмәләрне тапшырырга хокуклы.

Муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына керүче зат үзе тапшырган керемнәр, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр турында белешмәләрдә нинди дә булса мәгълүматлар чагылдырылмаган яки тулысынча чагылдырылмаган очракта, ул әлеге Нигезләмәнең 2 пункты нигезендә белешмәләр бирелгән көннән бер ай эчендә төгәлләштерелгән белешмәләрне тапшырырга хокуклы».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **И.Ф. Хафизов**

Юрист

Т.В.Токмакова
3 19 55